УДК 811.512.145′282

*А.Җ. Хөсәенова*

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ДИАЛЕКТЛАРЫНДА СОМАТИЗМНАР

В современном языкознании соматическая лексика характеризуется как определенная лексико-семантическая система, в которой отражаются знания, представления носителей языка о самом себе и своем организме. В статье рассматриваются вопросы изучении названий соматизмов в татарском языке и диалектах.

**Ключевые слова:** когнитивная лингвистика, терминологическая лексика, татарская лексикология, диалектная лексика, соматизмы.

Башка катламнар кебек ук, телнең сүзлек байлыгы да киң һәм күпкырлы системаны тәшкил итә, чөнки сүзлек составына бер-берсенә төрле мөнәсәбәтләр белән бәйләнгән күп лексик берәмлекләр керә. Тел аралашу чарасы буларак уңышлы кулланылсын өчен, лексика да аерым бер тәртиптә оешырга тиеш. Аның гомуми үсеше, кулланылыш өлкәсенең киңәюе билгеле бер дәрәҗәдә терминологик атамаларны туплау, үстерү, системага салуга бәйле. Галимнәр билгеләвенчә, хәзерге телләрдә барлыкка килүче 90% яңа сүзләр махсус лексиканы тәшкил итә. Шуңа күрә дә әлеге төр сүзләр күп кенә телче галимнәрнең игътибарын үзләренә җәлеп итәләр.

Хәзерге заманда телдә кеше факторын өйрәнүгә игътибар арта бара, имманент лингвистикадан телне кеше, аның аңы, фикер йөртүе, рухи-гамәли эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнештә өйрәнүне максат итеп куйган антропологик лингвистикага күчеш күзәтелә [Роль человеческого..., с. 8]. Шуңа бәйле рәвештә, соматизмнар да яңа аспектлардан чыгып өйрәнелә. Әлеге төр сүзләр, ягъни кеше тәне әгъзаларын, чир атамаларын атаган лексика – татар теленең иң кызыклы лексик-семантик төркемнәрен тәшкил итәләр. «Соматик» атамасы [грек *soma (somatos)* – җисем] биологиядә һәм медицинада «кеше җисеме белән бәйле» дигән мәгънәдә кулланыла, «психика» төшенчәсенә каршы куела. Тел белемендә соматизмнар XX йөзнең икенче яртысыннан өйрәнелә башлый. Алар күренекле телчеләрнең чагыштырма-тарихи, лингвокультурологик хезмәтләрендә төп тикшерү объекты, гадәттә тел системасында иң беренче чиратта аерып чыгарыла торган лексик катлам булып торалар.

Бу төр сүзләр телдә күп гасырлар дәвамында формалашкан төп сүзлек байлыгына карый һәм кешеләрнең тирә-як дөнья турында мәгълүмат биреп кенә калмый, ә аларның үзләре, үз организмнары турындагы белемнәрен дә чагылдыра. Кеше әйләнә-тирә мохиттә үз урынын турыдан-туры сизү органнары һәм тән әгъзалары ярдәмендә билгели. Алар-

ның атамалары телдәге башка күп кенә лексик берәмлекләр кебек борынгы катламны тәшкил итә. Кеше шушы танып белү «инструменты» ярдәмендә билгеле бер пространство һәм вакыт аралыгында, дөньяга карашын белдереп, үз урынын билгели. Әлеге процесста эталон ролен кеше тәненең структур ассиметриясен чагылдырган сизү, күрү органнары урнашкан алгы һәм арткы өлешләре үти [Богус, б. 8–9]

Соматик сүзләр телнең төп лексик фондына карый һәм алар арасында бик борынгы чорларга караганнары да, соңрак барлыкка килгәннәре дә бар. Бүгенге көндә анатомия һәм физиология терминнары күп кенә телчеләр тарафыннан тикшерелә. Биредә М. Корбангалиев, Р.М. Гатин, Р.Р. Шәмсетдинова, Ю.А. Кривощапова, Т.А. Трафименкова, П.Ш. Абдулхалимова һ.б галимнәрнең хезмәтләрен атап үтәргә мөмкин.

Шулай да, татар тел белемендә соматизмнар аерым аспектларда бик аз өйрәнелгән. Татар телендә кеше, кеше тәненең әгъзалары темасы Д.Б. Рамазанова тарафыннан «Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика» (2013) дигән хезмәтендә синхроник һәм диахроник планда, башка телләр белән чагыштырылып махсус тикшерелә. Галим соматизмнарны ике зур төркемгә бүлеп карый:

1) кешенең физик төзелешен, әгъзаларын белдерә торган сүзләр;

2) кешенең эчке дөньясын белдерә торган сүзләр [Рамазанова, 2013, б. 4].

Моннан тыш әлеге темага багышланган тикшеренүләр Ф.С. Баязитова, Л.Г. Габдрахманова, Л.И. Муравьева, Н.Г. Йосыпова, И.И. Сабитова, Г.Ч. Файзуллина, А.М. Ямалетдинова хезмәтләрендә урын ала. Ләкин татар соматик лексикасын бар яклап та комплекслы тирәнтен тикшерү киләчәк бурычы булып кала бирә.

Татар әдәби телендә һәм диалектларда нигездә бер үк соматизмнар кулланыла (*баш, кул, беләк, уч, бармак, аяк, сөяк, сеңер, җилек, арка, кабырга, бөер, йөрәк, күз, колак, борын* һ.б.). Мәгънәләре ягыннан да алар бер-берсенә туры киләләр. Әлеге лексик берәмлекләрне А.М. Кочеваткин классификациясе буенча [Кочеваткин, 2001] һәм атау объектының үзенчәлекләре нигезендә түбәндәгечә төркемләргә мөмкин:

**1. Сомонимик лексика** (грекча *soma* «тән», *onim* «исем, атама») – кеше тәненең өлешләрен атаучы сүзләр. **Арға** 1. Себ. арка (спина); 2. Арт (задняя часть). Чуал арғазына кирде. – твр. [Татар теленең..., б. 50]; **Бәбәнәк** II трх. Кул (рука). Чәчем белән җир себердем, бәбәнәгем белән җир казыдым (107 б.); **Бӧйын** тара. муен (шея) [Татар теленең..., б. 127].

**2. Остеонимик лексика** (грекча *osteon* «сөяк») кеше тәненең сөякләре һәм аларны тоташтырып торучы җисемнәр атамалары. **Арқа сабағы** перм. **арқа севәге** миш. д., **арқа сийәге** кмшл. Умыртка, умырткалык (позвоночник) Шәп қаты қайғының арқа сабағына зыйаны күп. – перм. Мына ушы тештән арқа сийәгем аwырта. – кмшл. [Татар

теленең..., б. 51]; **Арқа үзәге** минз. к.: **арқа чоқоры. Арқа чоқоры** мам. Арка сөяге (спинной хребет) [Татар теленең..., б. 51]; **Баш чирәбе** хвл,. мәл. баш сөяге (череп) [Татар теленең..., б. 105].

**3. Спланхнонимик лексика** (грекча *splanchna* «эчке органнар») кеше тәненең эчке органнары исеме. **Базык эчәге** т. я.-крш. юан эчәге (толстая кишка). Базык эчәге аwырта. (95 б.); **Баур** твр. бавыр (печень) [Татар теленең..., б. 104]; **Йōғы** брб.д. талак (селезенка) [Татар теленең..., б. 251].

**4. Ангионимик лексика** (грекча *angeion* «кан тамыры») – кеше тәненең кан тамырлары системасын атаучы сүзләр. **Қан** урт. д. кан (кровь) [Татар теленең..., б. 386]; **Қычу** дөб. кан басымы (кровяное давление). Әwәл қычу диләр ийе, қан басымы диләр хәзер [Татар теленең..., б. 451].

**5. Сенсонимик лексика** (грекча *sensus* «хис, тойгы») – кешенең сиземләү органнарын белдерүче сүзләр. **Ағыс** брб. д. Авыз (рот) [Татар теленең..., б. 20]; **Борын танаwы** дөб. Борын (нос). Борын танаwы җимерелмәсен, карап йөр [Татар теленең..., б. 129]; **Күс** себ. күз (глаз) [Татар теленең..., б. 358]; **Кылак** миш. д. колак (ухо) [Татар теленең..., б. 365].

**6. Чир атамалары. Аwыр төшү** 1. т.я. күзенең кызарып, яшь агып һәм эренләп авыруы (болезнь глаз: конъюктивит ). Күзенә аwыр төшкән, күзен дә ача алмый, бертуқтаусыз җәш аға, эрер қойола. – к.т. [Татар теленең..., б. 18]; **Әсбе** [рус. оспа] 1. Байк. чәчәк авыруы (оспа). Әсбә кара цир ул, бер керсә, кырып цыга ул йәш балаларны; 2. нрл. Сызлавык (фурункул, нарыв) [Татар теленең..., б. 88].

Мисаллардан күренгәнчә, сөйләшләрдә соматик атамалар өчен күп кенә семантик үзенчәлекләр хас булуга карамастан, әдәби тел белән уртаклыклар да шактый күп. Чөнки әлеге сүзләр нигездә номинатив характердагы конкрет мәгънәгә ия һәм аларга терминологиклык хас. Шулай да бередә аларның функцияләре киңәю, коннотатив, метафорик мәгънәләр барлыкка килүе дә күзәтелә.

Диалектларда соматик берәмлекләр, нигездә, аерым тән әгъзаларын яисә өлешләрен номинацияләүдә кулланылалар: *беләзеклек* «беләк сөяге», *дөбә (кабыргасы)* «нижнее грудное ребро» һ.б. Шул ук вакытта тән әгъзаларының аерым өлешләренең атамалары сүзтезмәләр белән дә бирелә: *уч табаны* «учның уртасы», *урта тийәк* «урта бармак», *айақ бите* «аяк табанының өске өлеше», *сакал севәге* «ияк сөяге», *арқа үзәге* «арка сөяге» һ.б. Алга таба әлеге сүзтезмәләр кушма сүзләргә әйләнәләр: *йанбаш* «оча сөяге», *йаналыш* «тын алу», *айагасты* «аяк табаны» һ.б.

Чир атамалары нигездә шулай ук әдәби тел белән туры килә. Мәсәлән: *авыру, чир* «болезнь» һ.б. Шуның белән бергә саф диалектизмнар да очрый:

*зыңқар* бгрс., кргл. (авыру). *Ике ел торгач, зыңкар булып китте* [Татар теленең..., б. 203];

*җыланкүз* перм. бармакка чыга торган шеш (нагноение

на пальце). Бармакка жыланкүз чыкты [Татар теленең..., б. 195];

*отыры* тбл. шайтан тырнагы (заусенец). Пармагына отыры цыгаты [Татар теленең..., б. 507] һ.б.

Семантик аспектта тикшерү диалектлар һәм сөйләшләрнең үзара бәйләнешле булганын һәм бер-берсенә тәэсир иткәнен күрсәтә. Мәсәлән, урта диалектта *кәсел кеше* дигән гыйбәрә бар. Ул «авыру, чирле кеше» дигән мәгънәне белдерә. Без сүзнең этимологиясе себер диалектларындагы *кәс* «начар, ахмак» дигән сүз белән бәйле дип саныйбыз. Мишәр диалектында әлеге сүз «булдыксыз, сәләтсез, уңмаган» мәгънәсен белдерә.

Тел үсеше барышында соматизмнарның семантикасы да киңәя. Моңа мисал итеп урта диалектның каргалы сөйләшендә *беләк* сүзендәге метафорик мәгънә көчешен китерергә мөмкин. Биредә ул «бер тапкыр кулга урарлык күләмдә җеп чыгарырлык кәҗә мамыгы» мәгънәсендә кулланыла: *Маңганнан соң, бер беләклек алып беләккә урыйлар эрләр өчен, ул беләк була* [Татар теленең..., б. 113].

Татар теле сөйләшләрендә соматизмнар болар белән генә чикләнми әлбәттә. Әлеге төр сүзләрне лингвоструктур һәм башка аспектларда тикшерү зур әһәмияткә ия. Чөнки әлеге атамалар халыкның рухи дөньясы, ышанулары, эстетик карашлары белән тыгыз бәйләнгән. Алар тел мәдәниятен, аның гамәли, фәлсәфи нигезләрен аңларга ярдәм итә, тел аша белдерелгән дөнья картинасы сурәтләрен ачып бирә.

**Әдәбият**

*Богус З.А.* Соматизмы в разносистемных языках: семантико-словообразовательный и лингвокультурологический аспекты (на материале русского, адыгейского и английского языков). Автореф. дис. ... канд. филол. наук. Майкоп, 2006. 32 с.

*Кочеваткин А.М.* Соматическая лексика эрзянского языка. Саранск: Красный октябрь, 2001. 200 с.

Роль человеческого фактора в языке. Язык и картина мира / отв. ред. Б.А. Серебренников. М.: Наука, 1988. 216 с.

*Рамазанова Д.Б.* Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика. Казан: ИЯЛИ, 2013. 364 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

***Хөсәенова Алина Җәмил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*